МИНИСТЕРСТВ
ЗЕМЕЛЬНЫХ И
ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ
МОНОСЭБОТЛЭРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

---

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

28.04.2023 Казан ш. № 1133-р

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәре объектының саклык зонасын урнаштыру турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекнең дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль законның 32 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Нижнекамскнефтехим» ГЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Фонд пространственных данных Республики Татарстан» ДБУның (26.04.2023 № 01А-04/968) хатын искә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карар чыгарды:

1. Газ бүлү челтәре объектының (001603 инвентарь номерлы бүлгеч газүткәргеч) саклык зонасын, территорияне файдалануның аерым шартлары

булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, гомуми мәйданы (68069 ± 4566) кв.м территория рәвешендә урнаштырырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләре объектының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

Министр в.б. А.И.Галиев